ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№242 от «26» 07 2021 г.

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү, коррупциячел хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итә торган чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында һәм «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру турында» дәүләт программасын раслау хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру турында» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 21 июнендәге 485 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р к а б у л и т т е:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы турында» 1622 санлы карарына (Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 11.05.2016 ел, №469; 05.09.2018 ел, №474; 21.11.2018 ел, №578; 05.09.2019 №231; 28.07.2020 №267 карарларындагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Исемендә, 1 пунктта «2015-2020» санын «2015-2024» санына алмаштырырыга»;

күрсәтелгән карар белән расланган «2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасында (алга таба – Программа):

Исемендә «2015-2020» санын «2015-2024» санына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлындагы «2015-2020» саннарын «2015-2024» санына алмаштырырга;

0000011002

«Программаны гамәлгә ашыруның вакыты һәм этаплары» юлындагы «2015-2020» саннарын «2015-2024» санына алмаштырырга;

«Программаны финанслау күләмнәре һәм аларны үтәү еллары буенча бүлү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Программаны финанслау күләме прогнозланган характерда һәм Мамадыш муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, Программа чараларын гамәлгә ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчалардан файдалану күздә тотыла.»;

программаның V бүлегендәге беренче, икенче абзацында «2020 елга» сүзләрен «2024 елга» сүзләренә алмаштырырга»;

программага кушымтада «2015-2020» саннарын «2015-2024» саннарына алмаштырырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов